**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

« 18 » сентябрь 2019 с. Тюлячи № 238

«2019-2026 елларга эчәргә яраклы суның сыйфатын билгеләнгән таләпләргә туры китерү» инвестиция программасын эшләүгә Теләче муниципаль районының Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты өчен техник биремне раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында» 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коммуналь комплекс оешмаларының инвестиция программаларын әзерләү буенча техник йөкләмәләр әзерләүгә методик тәкъдимнәрне раслау турында» Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгының 2007 елның 10 октябрендәге 100 номерлы боерыгы нигезендә,

1. Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты өчен «2019-2026 елларга эчә торган суның сыйфатын билгеләнгән таләпләргә туры китерү» инвестицион программасын эшләүгә техник биремне расларга.

2. Әлеге күрсәтмәне Теләче муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«18» 09 2019ел № 238
номерлы боерыгына
кушымта

# ТЕХНИК БИРЕМ

**Теләче муниципаль районының Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты өчен «2019-2026 елларга эчә торган суның сыйфатын билгеләнгән таләпләргә туры китерү» инвестицион программаны эшләүгә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «2019-2026 елларга эчә торган суның сыйфатын билгеләнгән таләпләргә туры китерү буенча» инвестицион программа проектын эшләүгә техник бирем (алга таба текст буенча - техник бирем, инвестицион программа) түбәндәгеләр нигезендә эшләнелде:

- Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексы;
- Россия Федерациясе Җир кодексы;
- «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон;
- «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон;
- «Коммуналь комплекс оешмаларының инвестицион программаларын эшләү буенча техник биремнәрне әзерләүгә методик тәкъдимнәрне раслау турында» Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгының 2007 елның 10 октябрендәге 99 номерлы боерыгы;
- Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгының «Коммуналь комплекс оешмаларының инвестицион программаларын эшләү буенча техник биремнәрне әзерләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2007 елның 10 октябрендәге 100 номерлы боерыгы;
- Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитария табибының 2001 елның 26 сентябрендәге 24 номерлы карары белән расланылган СанПиН 2.1.4.1074-01 «Торак урыннарны эчә торган су һәм су белән тәэмин итү. Эчә торган су, үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү сыйфатына карата гигиена таләпләре. Сыйфатның контроле. Санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормативлар»;
- РФ Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестицион һәм җитештерү программалары турында» 2013 елның 29 июлендәге 641 номерлы карары;
- «Салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы карары;
- Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 6 маендагы 198 номерлы карары белән расланган «2014-2020 елларга Теләче муниципаль районы коммуналь инфраструктурасын һәм торак фондын модернизацияләү» программасы.

## 2. Инвестицион программаны эшләүнең һәм гамәлгә ашыруның максат-бурычлары

2.1. «2019-2026 елларга эчә торган суның сыйфатын билгеләнгән таләпләргә туры китерү» инвестицион программаны эшләүнең һәм гамәлгә ашыруның төп максаты - эчәргә яраклы суның сыйфатын билгеләнгән таләпләргә туры китерүгә юнәлдерелгән чараларны үтәү.

2.2. Инвестицион программаны эшләү бурычлары:

- эчәргә яраклы суның тиешле күләмен һәм сыйфатын тәэмин итү, эчәргә яраклы суның сыйфатына карата норматив таләпләрне үтәү;

- яңа төзелә торган (реконструкцияләнә торган) капиталь төзелеш объектларының су белән тәэмин итү системаларына, билгеләнгән куәтләрнең гарантияләнгән күләме белән тоташтыруны тәэмин итү;

- сыйфатлы суны чыганактан кулланучыга кадәр өзлексез җибәрүне тәэмин итү;

- кулланучыларны Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитария табибының 2001 елның 26 сентябрендәге 24 номерлы карары белән расланылган, СанПиН 2.1.4.1074-01 «Торак урыннарны эчә торган су һәм су белән тәэмин итү. Эчә торган су, үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү сыйфатына карата гигиена таләпләре. Сыйфатның контроле. Санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормативлар»ы нигезендә сыйфатлы су белән тәэмин итү;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы карары белән расланган Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу кагыйдәләренең норматив таләпләре нигезендә су белән тәэмин итү системалары эшенең ышанычлылыгын арттыру.

- Югары Кибәхуҗа, Максабаш, Төрек-Тәмте авыл җирлекләрендә салкын су сыйфатын тәэмин итү чараларын Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитария табибының 2001 елның 26 сентябрендәге 24 номерлы карары белән расланылган СанПиН 2.1.4.1074-01 «Торак урыннарны эчә торган су һәм су белән тәэмин итү. Эчә торган су, үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү сыйфатына карата гигиена таләпләре. Сыйфатның контроле. Санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормативлар»ы нигезендә оештыру;

2.3. Инвестиция программасын эшләү һәм алга таба тормышка ашыру кулланучыларны су белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын, сыйфатын һәм куркынычсызлыгын арттыруны, аварияләрне һәм тузуны киметүне, үткәрүчәнлекне арттыруны һәм суның сыйфатын яхшыртуны тәэмин итәргә тиеш.

## 3. Максатчан индикаторлар һәм күрсәткечләр

3.1. Су белән тәэмин итү хезмәтләренең максатчан индикаторлары һәм сыйфат күрсәткечләре:

- эшкәртүдән соң эчә торган суның сыйфатын күтәрү:

* билгеләнгән таләпләргә туры китерү буенча гамәлләр планы;

* «2019-2026 елларга эчәргә яраклы суның сыйфатын билгеләнгән таләпләргә туры китерү буенча» инвестицион программаны программада билгеләнгән срокларда Максабаш, Төрек-Тәмте торак пунктларында, катгыйлык күрсәткече - 10 белән гамәлгә ашыру, Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитария табибының 2001 елның 26 сентябрендәге 24 номерлы карары белән

расланылган СанПиН 2.1.4.1074-01 «Торак урыннарны эчә торган су һәм су белән тәэмин итү. Эчә торган су, үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү сыйфатына карата гигиена таләпләре. Сыйфатның контроле. Санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормативлар»ы һәм түбәндәге күрсәткечләр буенча расланды:

гомуми минерализацияләү (коры калдык) 1000 (15000) мг/л;

гомуми катылык7,0 (10) мг-экв./л;

тимер – 0,3 (1,0) мг/л;

сульфатлар – 500 мг/л;

төслелек – 20 (35) градус;

болганчыклык– 2,6 (3,5) ЕМФ яки 1,5 (2) мг/л;

микробиологик күрсәткечләр буенча канәгатьләнерлек булмаган пробаларның процентын 0,5 %ка киметү.

## 4. Инвестицион программага таләпләр

4.1. Инвестицион программаның рәвеше һәм эчтәлеге РФ Хөкүмәтенең 2013 елның 29 июлендәге 641 номерлы «Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция һәм җитештерү программалары турында» карарына һәм әлеге техник бирем таләпләренә туры килергә тиеш.

4.1.1. Инвестицион программа түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) инвестицион программаның паспорты;

2) су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системалары объектларын проектлау документациясен әзерләү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү чаралары исемлеге, инвестиция программасы чараларының кыскача тасвирламасы, шул исәптән аларның кирәклеген нигезләү, су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларының реконструкцияләнә һәм яңартыла торган объектларын тасвирлау (урнаштыру урыны), мондый объектларны бер төрле идентификацияләүне тәэмин итә, мондый объектларның төп техник характеристикаларын сыйфатлау чараны гамәлгә ашыруга кадәр һәм аннан соң да башкарыла;

3) су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларын һәм аларның аерым объектларын техноген, табигый характердагы һәм террорчылык актларыннан яклау, авария хәлләрен барлыкка килүне булдырмау, гадәттән тыш хәлләрнең куркынычын киметү һәм нәтиҗәләрен йомшарту чаралары;

4) үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системалары объектларын файдалануга тапшыру графигын да кертеп, инвестицион программа чараларын гамәлгә ашыру графигы;

5) инвестицион программаны гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс ихтыяҗлары күләме турында, инвестиция программасының аерым чаралары буенча бүленеп, инвестиция программасын финанслау чыганаклары күрсәтелгән, белешмәләр;

6) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру чаралары планы һәм программасы;

7) инвестицион программа тасвирлау һәм таблица өлешләреннән торырга тиеш;

8) су белән тәэмин итү системалары буенча техник чаралар планы, су белән тәэмин итү системаларының торышын һәм аларны эксплуатацияләү шартларын

максатчан индикаторлар бирә торган дәрәҗәгә җиткерүне тәэмин итә һәм төзелеп килүче (үзгәртеп корыла торган) объектларны су белән тәэмин итү системаларына тоташтыра;

9) инвестицион программаны тормышка ашыру вакыты.

4.1.2. Инвестицион программага түбәндәге максатларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чараларны кертергә кирәк:

1) эчәргә яраклы суның сыйфатын арттыру;

2) су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системалары объектларын бүлеп, су белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын күтәрергә, аларны яңартырга яисә реконструкцияләргә кирәк;

3) су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системалары объектларының энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру;

4) су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларын һәм аларның аерым объектларын техноген, табигый характердагы куркынычлардан, террорчылык актларыннан яклау, авария хәлләрене булдырмау, гадәттән тыш хәлләрнең куркынычын һәм нәтиҗәләренең аянычлылыгын киметү.

4.1.3. Инвестицион программаны эшләү барышында түбәндәге белешмәләрдән һәм хисаплардан чыгып эш итәргә кирәк:

1) Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегенең генераль планы;

2) Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 6 маендагы № 198 номерлы карары нигезендә расланган, Теләче муниципаль районында 2014-2020 елларга коммуналь инфраструктура һәм торак фонды модернизациясе планы;

3) Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авылының су белән тәэмин ителеш схемасы;

4.2. Инвестицион программаны эшләү барышында түбәндәгеләрне эшләү зарур:

- үтәлергә тиешле таләпләр нигезендә, эчә торган суның сыйфатын яхшыртуга зыян салучы проблемаларны күрсәтеп, су белән тәэмин ителеш системаларының бүгенге халәтенә анализ ясарга;

- эчә торган суның сыйфатын куелган таләпләргә туры китерү буенча гамәлләр планын эшләргә, әлеге планны, киләсе елның 1нче июленә кадәр, федераль башкарма хакимият органының, федераль дәүләт санитар-эпидемиологик күзәтчелеген башкаручы, территориаль органы белән килештерергә.

Эчә торган суның сыйфатын куелган таләпләргә туры китерү буенча гамәлләр планы инвестицион программага кертелә.

- Инвестицион программа гамәлләрен тормышка ашыру өчен кирәк булган финанс ихтыяҗлары күләмен билгеләргә:

1) инвестицион программа гамәлләрен тормышка ашыру буенча кирәк булган финанс ихтыяҗлары күләмен, һәрбер гамәл өчен кирәкле финанс ихтыяҗы күләмнәрен суммарлаштырып билгеләргә;

2) инвестицион программа гамәлләрен тормышка ашыру өчен кирәк булган финанс ихтыяҗларын төзелеш һәм реконструкция бәясенең зурайтылган күрсәткечләре, гамәлдәге смета норматив базасы (дәүләт элемент нормалары, федераль берәмлек бәяләре) нигезендә билгеләргә.

4.3. Инвестицион программаны финанслау чаралары булып, түбәндәгеләр торырга мөмкин:

- Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитетының шәхси чаралары;

- тарифларга тоташтыру һәм өстәлмәләр кую нигезендә, тарифлардан алынган финанс чаралары;

- федераль, региональ, муниципаль максатчан программаларны тормышка ашыру барышында билгеләнгән финанс чаралары.

4.4. Инвестицион программада финанс ихтыяҗларының, билгеләнгән финанс чыганаклары буенча бүленешен, шулай ук инвестицион программаны тормышка ашыруның елларга, этапларга бүленешен дә күрсәтергә кирәк.

4.5. Тормышка ашырыла торган инвестицион программа гамәлләренең, башка программалар эчендә, ике төрле хисабы килеп чыкмасын өчен, эшләнелә торган инвестицион программаның сәнәгать программасы белән килешенүен тәэмин итәргә.

4.6. Инвестицион программа буенча эшләрне координацияләүне Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты һәм Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты башкара.

4.7. Инвестицион программаны тормышка ашыру срогы – 2019 елның 1 октябреннән – 2026 елның 31 декабренә кадәр.

4.8. Инвестицион программаның проектын, кирәкле финанс ихтыяҗларының хисабын, тарифларга өстәлмәләрне һәм тоташтыру буенча тарифларны территориаль орган белән килештерү зарур.

4.9. Финанс ихтыяҗлары, инвестицион программа гамәлләрен үткәрү белән бәйле булган барлык чыгымнар комплексын үз эченә ала:

- проект-тикшеренү эшләре;
- материаллар һәм җиһазлар сатып алу;
- төзелеш-монтаж эшләре;
- техник-икътисадый характеристиканы яхшырткан җиһазларны алыштыру эшләре;
- җибәрү-көйләү эшләре;
- объектларны теркәүне үткәрү;
- төп гамәлләр (төзелеш чорына җирне арендалу һ.б.) бәясенә кермәгән чыгымнар;

4.10. Инвестицион программа һәрбер гамәле өчен финанслау чыганакларын булдырырга тиеш.

4.11. Гамәлләрнең бәһасе, аларны үткәрү елындагы бәяләргә бәйле рәвештә китерелергә тиеш.

## 5. Инвестицион программаны тормышка ашыру срогы

Инвестицион программаны тормышка ашыру срогы – техник биремне раслаган көннән алып өч ай дәвамында.

## 6. Инвестицион программаны эшләүче

Инвестицион программаны эшләүче – Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авылы башкарма комитеты.

## 7. Техник биремгә үзгәрешләр кертү тәртибе

7.1. Расланган техник биремне кабат карап чыгу (үзгәрешләр кертү) Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты яисә Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге бакарма комитеты инициативасы белән башкарыла.

7.2. Расланган техник биремне кабат карап чыгу (үзгәрешләр кертү) өчен түбәндәгеләр нигез булып тора ала:

- Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 6 маендагы № 198 номерлы карары нигезендә расланган, Теләче муниципаль районында 2014-2020 елларга коммуналь инфраструктура һәм торак фондын модернизацияләү Программасына үзгәрешләр кертү;
- техник биремнең шартлары үзгәрүенә китергән, башка муниципаль программаларга үзгәрешләр кертү;
- техник биремне раслау вакытында, коммуналь инфраструктура системасына кушылган төзелеш объектларының, инженерия инфраструктурасы белән тәэмин ителгән җир кишәрлеге исемлекләренең яңаларын өстәү һәм (яисә) кабул ителгәннәрен төшереп калдыру.

7.3. Техник биремне кабат карап чыгу (үзгәрешләр кертү) елга бер тапкыр гына үткәрелергә тиеш.

7.4. Әгәр техник биремне кабат карап чыгу Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты инициативасы белән башкарылса, кабат карап чыгуның (үзгәрешләр кертү) мөһимлеген һәм сәбәпләрен аңлаткан гариза, тиешле документлар беркетелеп, Теләче муниципаль районы Башкарма комитетына юллана.

## 8. Инвестицион программаны тәкъдим итү формасы

Инвестицион программа, ризалык алу өчен, Теләче муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрелә.

Теләче муниципаль районы
Башкарма комитеты
эшләре идарәчесе И.Т. Хадиев